وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

№4 (121). 27 гыйнвар 2012 / 4-раббигыль-әүвәл-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



*Коръән елы:*
Болгар чоры изге китап күчермәсе реставрация көтә
▷2◁



Ачлык елында балалар язмышы
▷3◁



"Китапка хөрмәт Коръәннән башланган"
▷4◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

**ЧАЛЛЫ**

Мәүлид ае уңаеннан, мөхтәсибәтнең Нур-Ихлас мәчетендә, ГЭС мәхәлләсендә, шулай ук Әбүзәр мәчете янындагы пансионатта "Мөнәҗәт кичәсе" оештырылачак.

"Мондый кичә мөхтәсибәттә беренче тапкыр үткәрелә, шуңа да махсус әзерлекләр бара. Чарага олы һәм урта буын вәкилләрен генә түгел, яшьләрне дә кызыксындырырга тырышачакбыз, шул рәвешле буыннар арасындагы бәйләнешне яңартырбыз дигән өмет бар", - дип билгеләп үтте Чаллы имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин.

**КАМА ТАМАГЫ**

Районның Җәмигъ мәчетендә ислам дине нигезләре буенча курслар дәвам итә. Имам-мөхтәсиб хәбәр иткәнчә, дүшәмбе, сишәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә укуларга хатын-кызлар йөри. Ир-атлар пәнҗешәмбе көнне җыела. Мөселманнарга уңайлы булсын өчен, курслар ахшам намазыннан соң - кичке вакытта үткәрелә.

Мәүлид ае уңаеннан, авыл мәчетләрендә дә бәйрәм мәҗлесләре оештырылачак.

**БАУЛЫ**

Биредә мәктәп укучылары арасында иң яхшы рефератка бәйге игълан ителгән. Иҗади эшнең темасы - пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) тормышы. Район имам-мөхтәсибе Исмәгыйль хәзрәт Биккинин билгеләп үткәнчә, киләсе атна башында мөхтәсибәттә имам-хатыйблар җыелышы узачак.

**ТҮБӘН КАМА**

РИУ, килешү буенча, Түбән Кама шәһәрендәге "Рисалә" мәдрәсәсе шәкертләрен уку әсбаплары белән тәэмин иткән. "Вәгъдә ителгән китапларның әлегә бер өлеше генә кайтса да, булганнарын инде шәкертләрнең кулларына тапшырып, уку-укыту барышында куллана башладык", - диде мәдрәсә директоры Рафикъ хәзрәт Исламгалиев.

**ӘГЕРҖЕ**

Мәүлид ае кысаларында районның Җәмигъ мәчетендә 28 гыйнвар көнне мөселманнар җыены үтәчәк.

Якын көннәрдә мөхтәсибәттә имам-хатыйблар җыелышы да узачак. "Җыелышта үткәреләсе чаралар, дини-агарту эшләре, мөселманнарны борчый торган көнүзәк мәсьәләләрне яңабаштан карап чыгачакбыз һәм үзара фикер алышачакбыз", - дип билгеләп үтте Әгерҗе мөхтәсибе Ранил хәзрәт Якупов.

**МӨСЛИМ**

Мөслим мөхтәсибе Мөнир хәзрәт Борһанов хәбәр иткәнчә, биредә сәламәт яшәү рәвеше алып баруга зур игътибар бирелә. Мөселман яшьләре өчен дүшәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә спортзалга, якшәмбе - бассейнга йөрү оештырылган. Шул рәвешле, мәчет каршындагы дини укулар физик күнегүләр белән бергә чиратлаштырып алып барыла.

**ЧИСТАЙ**

Узган атна ахырында район имамнары катнашында мөхтәсибәт утырышы булып узган. Мөгаллимнәр белән уку-укыту программаларының Дания нәзарәте тәкъдим иткән программаларга туры килү-килмәве ачыкланган. Теркәү документлары буенча имамнар белән күп кенә сорауларга ачыклык кертелгән. Муллаларга брошюра рәвешендә җомга вәгазьләре таратылган.

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***



# МӘҮЛИД АЕ МӨБАРӘК БУЛСЫН!

**Аллаһы Сүбхәнәһү вә Тәгаләгә мактауларыбыз булса иде! Әссәламегаләйкем вә рахмәтуллаһи вә бәрәкатүһү! Мөхтәрәм дин кардәшләребез!**

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән барлык мөселманнарны да Раббигыль-әүвәл ае башлануы белән ихластан котлыйм!

Бу ай - Аллаһы Тәгаләнең сөекле рәсүле, Ахырзаман пәйгамбәре Мөхәммәд (сгв) дөньяга килгән ай. Шуңа күрә Раббигыль-әүвәл ае исламда әһәмиятле айларның берсе санала. Коръән ашлары, дини мәҗлесләр үткәрү, бергә җыелып Пәйгамбәребезгә (сгв) салаватлар әйтү, дога кылу - бу айның күркәм гадәтләреннән. Татарстан мәчетләрендә, мөселман уку йортларында, мөселманнар яшәгән һәр йортта бу матур дини йолалар гасырлар буе сакланып килә.

Раббигыль-әүвәл аеның могҗизасы - Пәйгамбәребезнең (с.г.в) туган көне. Аны ислам динендә Мәүлид дип атыйлар. Әлеге көн мөселманнарны изге, игелекле гамәлләр кылырга чакыра. Пәйгамбәребезнең (с.г.в) тормыш-яшәеше һәр мөселман өчен өлге, үрнәк булып тора. Ул үзенең кылган гамәлләре белән мөселманнарны сабырлыкка, ихласлылыкка, рухи кыйммәтләрне сакларга чакырды. Аның тормыш юлы, һәр гамәле - яшәешебезнең нигезе. Пәйгамбәребезнең (сгв) һәр сулышы, һәр сүзе мөселманнар өчен аерым мәгънәгә, зур кыйммәткә ия. Ул кушканнарны үтәп, без рухыбызны гына чистартып калмыйбыз, ә әхлак югарылыгына ирешәбез, игелекле гамәлләребезне арттырабыз.

Барчабызга да Кыямәт көнендә Аллаһы Сөбхәнәһү вә Тәгаләнең рәхим-шәфкатенә һәм Пәйгамбәребезнең (сгв) шәфәгатенә ирешергә насыйп булса иде.

Аллаһы Сөбхәнәһү вә Тәгалә һәрбарчабызга да иман ныклыгы, ике дөнья бәхете насыйп әйләсә иде. Барлык изге эшләребез һәм башлангычларыбыз да Аллаһы Тәгаләнең рәхим-шәфкате белән эшләнсә иде.

***Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***

# МиллилекМЕ, динилекМЕ?

**Россиядә соңгы ике дистә елда мөселманнар арасында миллилек мәсьәләсе алгы чиккә чыга бара, бәхәсле проблемага әйләнә, чөнки Татарстан, Башкортстаннан тыш, мәчетләрне татар телле булудан актив рәвештә рус телле итүгә көчлиләр. Әгәр инде моңа каршы нәрсәдер әйтелсә, татарны милли эгоизмда гаепләп кенә калмыйча, тагын бер үтергеч аргумент китерәләр: "Совет вакытында сез дини белемне югалттыгыз, сездә дин калмады", - дип авызны ябарга омтылалар.**

Алай икән, ислам динендә телгә мөнәсәбәтнең нинди леген, бәлкем, чит илләрдән карарга кирәктер? Ул урыннарда динне тыю бездәге белән чагыштырганда, юк диярлек иде, димәк, аларның дин галимнәре хата эшләмәгәннәрдер, телгә дөрес караштa торгандыр?

Беренчедән, Баңладеш мисалын карап үтик. Ул бүгенге көндә бәйсез дәүләт, "баңладеш" сүзе үзе үк "бәңгалиләр иле" дип тәрҗемә ителә. Бәңгали милләте вәкилләре Баңладештан тыш шулай ук Көнбатыш Бәңгалия исемле Һиндстан штатында да яшиләр. XX гасырның уртасына хәтле Бәңгалия Һиндстан составында иде, ә ул үз чиратында инглиз колониясе иде. Мәгълүм ки, 1947 елда Һиндстан бәйсез дәүләт итеп игълан ителде, әмма аның территориясе дини билгеләмә буенча бүленде: мөселманнар яши торган урыннар Пакыстан дәүләтен тәшкил итте, димәк Һиндстан исемле инглиз колониясе нигезендә ике бәйсез дәүләт хасил булды: Һиндстан һәм Пакыстан.



Бүгенге бәйсез Баңладеш дәүләте 1971 елның 26 мартында барлыкка килде: ул бердәм Пакыстан Ислам Республикасы исемле дәүләттән бүленеп чыкты. Ни өчен соң Ислам дәүләте бүленде? Баңладеш булган Көнчыгыш Бәңгалиядә мөселманнар гына яши ич? Көнбатыш Бәңгалиядә исә индуист булган бәңгаллар калды.

Димәк әле чагыштырмача безгә якын заманда дөньяда яңа милләт калыпланды - баңладешлар - алар бер телдә сөйләшсәләр дә, Көнбатыш Бәңгалия халкыннан аерым, чөнки диннәре төрле һәм пакыстанлылардан да аерылдылар, чөнки бер диндә булсалар да, телләре аерым.

Баңладеш җирлегендә Ислам әле XIII гасырда ук тарала башлый. Аны җирле бәңгаллар бик теләп кабул итә, чөнки халыкны касталарга бүлгәләгән индуизм дине гаделсез дип санала. Исламны дәгъват итү үз нәтиҗәсен бирә: инглиз колонизаторлары 1872 елда үткәрелгән җанисәп алу мәгълүматларына караганда, Бәңгалиядә ул вакытта мөселманнар күпчелекне тәшкил иткән.

Бер провинцияне тәшкил иткән Бәңгалия дини состав буенча икегә аерымлана башлый: көнбатышта - индуистлар, ә көнчыгышта - мөселманнар күпчелекне тәшкил итә.

1906 елда Даккада Һинд мөселман лигасы оештырыла. XX гасырның башында ук инглизләр "бүлгәлә һәм хакимлек ит" принцибыннан чыгып, Бәңгалияне икегә бүләргә теләделәр, мөселманнар моны хуплады, индуслар исә каршы чыкты: алар бердәм мәдәни мирас турында һәм бердәм бәңгәл милләте турында тукыды.

Һиндстан исемле британ колониясе бәйсезлеккә бару процессында икегә бүленде - ул вакытта бәңгаллар башка мөселман халыклар белән бергәләп яңа шәргый дәүләт коруга тотындылар, аңа исемне дә Пакыстан дип, ягъни "чиста ил" дип куштылар.

Шул бердәм Пакыстан ике - Көнбатыш һәм Көнчыгыш өлештән гыйбарәт иде.

Бер дәүләт кысаларда бәңгаллар үзләрен кимсетелгән дип тиз хис итә башлады, чөнки 1948 елда урду теле - бердәнбер дәүләт теле буларак игълан ителә. Фәкать 1954 елда гына бәңгал теле икенче дәүләт теле статусына ирешә ала. Күрәбез ки, халыкның туган телен кимсетү, санга сукмау сәяси нәтиҗәләргә китерә. Пакыстанның ике өлеше ерагая бара һәм, ниһаять, 1971 елда хәтта үзара сугышка барып җитәләр.

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

# МиллилекМЕ, динилекМЕ?



*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

1971 елда азатлык сугышында бәңгаллар җиңә һәм Бәңладеш дәүләте пәйда була.

Шушы тарихи вакыйгалардан гыйбрәт алырга кирәк - һәр халык үз туган телен хөрмәт итә, аны сакларга омтыла. Һәм дини бердәмлек идеясен битлек итеп файдаланып, башка халык телен кимсетү озакка сузыла алмый шул. Үзара нәфрәт барлыкка килә. Безнең Россия шартларында да татар телле мәчетләрне саклыйсы иде. Бәңгалларны дини яктан надан дип әйтеп булмый ич - аларда атеизм чоры булмаган, алар һәм мөселманнар, һәм бәңгаллар булып калырга теләде бит. Ислам солидарлыгы, ихванлыгы өчен телләреннән ваз кичмәде. Татарларга да андый хокук бирелергә тиеш кебек.

Тел ягыннан тагын мисаллар китереп була, мәсәлән, көрдләр: алар да Гыйрак эчендәге дәүләт теленә - гарәп теле, Коръән теле дип мөкиббән китмәде, ә үз туган телләре өчен корал тотып сугышып хәзер фактта табигый статуска ия булды: һәм көрдләр, һәм мөселманнар булуга ирештеләр.

Россиядә татар мәчетләрендә туган телне кысрыклау тәҗрибәсе хәзер үзенә күрә бөтендөнья күләмендә бер казаныш булып таныла. Менә ни өчен татар ваһһабиларын бик теләп башка илләргә интенсив рәвештә дәшәләр, чөнки алар ваһһабилыкның эффективлыгын күрсәтүче экспонат ролен үти.- Милли үзенчәлектән колак кагу, миллилекне җую кебек феномен бик күп көчләрнең хыялы. Ул максатка күп дәүләтләр ирешергә тели - үз азчылыкларны эретү максатында. Шуның өчен, әлбәттә, татар ваһһабиларның "изге рус" телен мөкатдәс санаулары, туган телләреннән ваз кичүләре шундый бердәм кызыксыну һәм теләктәшлек уятты, кайберәүләрдә сүнеп барган өметләрен ялкынландырды.

Якын киләчәктә без менә шушы сәяси заказ барлыгын белеп, аңлап эш итәргә тиешбез. Татар телле мәчет феноменын саклау - ул глобаль үлчәмле бер вазифадыр. Татарларга һәм татар, һәм мөселман булып сакланасы иде. Ул вакытта миллилек белән динилек арасында каршылык юкка чыгар иде.

***Вәлиулла ЯКУПОВ,***
***тарих фәннәре кандидаты***

# Мин кем?

**Ерактагы кояш яктырак дигәндәй, без еш кына чит илләр, ерак халыклар тарихын үз тарихыбыздан да яхшырак беләбез. Таныш булмаган яклар безне күбрәк кызыксындыра.**

Болгар турында мин беренче тапкыр әниемнән ишеттем. Дөресрәге, ул язганнардан укыдым. Болгар минем күз алдыма мул үләннәрдә уйнаклаган атлар, кулына елан чыбыркы тоткан тиен бүрекле малайлар, ауга барырга җыенган ир-егетләрдәй шаулый торган урман, тынгысыз Идел булып килеп басты. Тарих дәресләрендә дә мин Болгар вакыйгаларын әнә шул җирлеккә куеп күзаллый идем.

Болгарны беренче тапкыр X сыйныфта укыганда күрдем. Физкультура укытучыбыз безне җыенга алып барды. Идел буенда тирмәләр корып (ул тирмәләрнең солдат палаткалары булуы бу очракта мөһим түгелдер) урнашканнан соң, без учакка утын эзләргә дип таралыштык. Дөрес, утын - сәбәп кенә иде. Асылда, һәркайсыбыз Болгар чорыннан калган чүлмәк кыйпылчыклары, Алтын Урда чорыннан калган тәңкәләр тапмабызмы дип өметләндек. Без тапсын диеп качып калган берәр тәңкә булырга тиештер бит инде? Ләкин мин, артык хыялланыпмы, бөтенләй башка якка китеп барганмын. Беренче тапкыр җәмәгать намазын күрүем шунда булды. Андагы ак яулыклы әбиләрнең берсе: "Бабаларыбыз ислам динен шушы туфракта кабул иткәннәр", - дип аңлатты. Аңа кадәр әле минем Ибне Фадлан язмаларын укыганым юк иде.



Соңрак, инде университетта укыганда, бу җиргә ешрак килә (кайта?) башладык. Остазыбыз Гамирҗан абый Дәүләтшин лекцияләреннән соң, Болгар безнең өчен Татарстандагы матур урыннан бигрәк, үткәнебез яши торган кадерле җирлеккә әверелде. Һәм үзебезнең кем булуыбызны, ни өчен шушы туфракта яшәвебезне онытмас өчен, Болгарга сокланырга гына түгел, ә аны сакларга да кирәклеген аңладык.

***Йолдыз МИҢНУЛЛИНА,***
***шагыйрә***

## КОРЪӘН ЕЛЫ:

# Болгар чоры изге китап күчермәсе реставрация көтә

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан 2012 ел - Коръән елы дип игълан ителде. Шул уңайдан, "Intertat.ru" газетасында изге китапның татар халкы белән бәйле бай тарихына, басылу-таралу үзенчәлекләренә багышланган язмалар сериясе дә башланды.**



## Китапханә байлыгы кульъязмалардан башлана

Казан (Идел буе) федераль университетындагы Н.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәнең кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге серле бер китап мәгарәсен хәтерләтә. Биредә шәрык кульъязмасын җыю традициясе 1807 елдан башлана, узган гасырның утызынчы елларында университет китапханәсенә татар голәмәләренең шәхси милкендәге гарәп шрифтында булган кульъязмалар һәм китаплар керә. 1963 елдан башлап университетның татар галимнәре Россиянең төрле төбәкләренә оештырылган археографик экпедицияләр вакытында табылган меңләгән китаплар тупланган.

Кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге баш китапханәчесе, 1803 елда дөнья күргән һәм "Казан басмасы" дип танылган беренче басма Коръәннең 2005 елда репринт нөсхәсен эшләүче Нурия ханым Гәрәева әйтүенә караганда, бүгенге көндә Казанда гарәп шрифтындагы татар, гарәп, фарсы телләрендәге барлыгы 25 меңнән артык кульъязма тупланган. "Бу сан Казан дәүләт коллекцияләрен Россия киңлекләрендә беренче урынга чыгара. Сан ягыннан Дагстанда кульъязмалар ике мәртәбәгә күбрәктер, әмма бер үзенчәлек бар - андагы коллекцияләр күбесенчә шәхси милектә", - ди ул.

Казан университеты китапханәсендә җыелган кульъязма саны 13 меңнән арта. Шуларның иң күп өлешен татарча язган китаплар тәшкил итә. Гарәп телендәге күчерелмә китаплар алардан азрак. Фарсы телендәгеләр чагыштырмача күпкә ким, чөнки фарсылар үзләре дә гарәпчә язганнар. Бөтен мөселман халыклары дини, фәнни әсәрләрне гарәп телендә язарга тырышканнар. Ул мөселман көнчыгышында фән теле булган. Әмма соңга таба, XV-XVI гасырлардан алып, төрки-фарсы телләрдә язылганнары арта бара.



Китапханәдә саклanучы борынгы кульъязмалар арасында изге китап - Коръән күчермәләре аерым игътибарга лаек. Нурия ханым алар белән таныштыра башлаганчы: "Бөтен мөселман халыклары Коръән укый. Ул мөселманнар өчен Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән, юл күрсәткеч, бердәнбер изге китап. Коръәннән дә күбрәк мәртәбә күчерелгән башка китап юк. Күчереп язылганнарның ни хәтлесе безнең көннәргә килеп җиткән - бу инде башка мәсьәлә. Тарихка күз салсак, татар халкы күп фаҗигаләргә дучар булган. Болгарны җимерә башлаган монгол яулары, Казан ханлыгының җимерелүе, рус хөкүмәтенең татарларга каршы алып барган колониаль сәясәте, совет дәүләтенең икейөзлелеге... Иң беренче чиратта халыкны борынгы тарихыннан, диненнән, дин белән бәйле мәдәниятеннән аерырга тырышканнар, халыкны әйдәп барырлык шәхесләрен, галим-голәмәсен кисеп, корбан итеп бардылар", - диде.

Шулай итеп, халкыбызның язма (әдәби, фәнни, дини) мирасы зур зыян күрә: китапханәләр хәрабәгә әйләндерелгән, татарларның бик күп китаплары яндырылган (йөзләрчә мәчетләребез китапханәләре белән бергә ут белән юк ителде). Моннан тыш бик кырыс табигый шартлар кульъязмаларның юкка чыгуына бер сәбәп булып тора. Табигый материалдан, мамыктан эшләнгән кәгазьгә язылган булганга күрә, тиешле дәрәҗәдә сакланмасалар бик тиз чериләр.

Шулай да, безнең көннәргә килеп җиткән уникаль нөсхәләр бар, китапханәдә аларны күз карасыдай кадерләп тоталар. Китапханәдә изге китап күчермәләре барлыгы йөз илледән артып китә. Миңа калса, кайбер кульъязмаларны басмалардан аерып булмый, чөнки алар шул кадәр вак, нәфис бизәкләр белән бизәлгән һәм тигез, камил итеп кулдан язылган, гаҗәпкә каласың.

## Курганнан кайткан изге китап

1982 елда Курган өлкәсендәге Әлмән авылыннан алып кайтылган Коръән кульъязмасы уникаль табылдыкларның берсе. Әлеге борынгы изге китапны университетның экспедиция төркеменә Әлмән авылында яшәгән Шәрифә Таҗетдинова тапшырган.

Шәрифә ханымның әти-әнисе узган гасырның утызынчы елларында Себергә сөргенгә җибәрелгән. Туган авылына кыз бары тик берничә дистә еллар узгач кына әйләнеп кайта алган. Ул борынгы китапның Коръән булуын белеп, аны яулыкка төреп, чоланында тычканнар тимәслек итеп элеп саклый. Китапның әлеге гаиләгә ничек килеп эләккәне билгесез. Ә менә тарихчылар күзлегеннән караганда, изге китапның Курган өлкәсенә барып чыгуы бер дә сәер хәл түгел. Чөнки татарлар Казан ханлыгы җимерелгәч, шулай ук XVIII гасырда казаклыкка язылгач бу якларга күпләп күченәләр.

Әлеге күләмле кульъязма китап (181 кәгазь, бер битенең якынча зурлыгы: 320 мм/ 250 мм) Коръәннең икенче яртысын тәшкил итә. Текстның ахырында күчермәнең кайсы елда эшләнгәне курсәтелмәгән. Әммә палеографик билгеләр (кәгазь сыйфаты, язу үзенчәлекләре һәм башкалар) бу нөсхә XVI-XVII гасырлар киселешендә эшләнгәнен шиксез раслый икән. Бик тә оста каллиграф тарафыннан язылган кульъязма булган. Ләкин ул шактый зыян күргән.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# АЧЛЫК ЕЛЫНДА БАЛАЛАР ЯЗМЫШЫ

## (Татар "голодомор"ына - 90 ел)



**ТАССР төзелүнең беренче елларында (XX гасырның егерменче еллары) татар халкы кичергән ачлык фаҗигасе - тарихыбызның иң коточкыч, иң авыр битләредер. Бу хакта галимнәребез язды инде һәм, сәбәпләрен анализлап, дөрес бәя дә бирделәр. Тик шушы афәт вакытында балаларга һәм бигрәк тә сугыш ятимнәренә игътибар ничек булуы, аларны саклап калу өчен нинди чаралар күрелүе хакында махсус хезмәтләр юк дияргә була. Дөрес, архивларда кайбер материаллар саклана әле.**

Искә төшерик: Россия, шул исәптән Казан губернасы 1914 елдан бирле өзлексез сугыш хәлендә. Халык хуҗалыгында төп көчләр булып күбрәк хатын-кызлар кала (ирләрне гомуми мобилизация белән сугышка алып торалар). Атлар да, эш кораллары да җитешми, тиешенчә эшкәртелмәгән җирдә иген уңышы кими. Ә җитештерелгән ашлыкны "бүлешүче"ләр күбәя. Мәгълүм булганча, ВЦИКның (БҮБК) 1918 елның 13 маенда кабул ителгән декреты нигезендә авылларга продотрядлар җибәрелә, һәм халыктан икмәк җыю кампаниясе башланып китә. Ә 1919 елдан, продразверстка планы кертелеп, икмәк крестьян хуҗалыкларыннан көчләп, мәҗбүриләп алына башлый һәм сугыш беткәнчегә кадәр дәвам итә. Дөрес, Совет хөкүмәте икмәкне промышленность товарларына (чәй, шикәр, тоз, керосин, мануфактура һ.б.) алыштырырга вәгъдә бирә-бирүен, тик ул тормышка ашырылмый. Шунлыктан крестьяннарда икмәкне күпләп җитештерүгә кызыксыну да кими төшә.

1920 елда бик авыр сәяси һәм икътисади шартларда Татарстан республикасы оеша. Бу ел тарихта корылык елы булып та кереп кала. Әмма табигать шартлары авыл хуҗалыгы өчен бик кыен булуга карамастан, 1920 елның башында ук Татарстанга 10 миллион 120 мең пот икмәк хәзерләү планы йөкләнә. Башында Сәхипгәрәй Сәетгалиев торган Татарстан хөкүмәте шушы планны үтәргә керешә. Республикада өч продтрибунал оеша. Алар, теләсә кайсы вакытта хөкем чыгарырга вәкаләтле булып, теләсә кемне төрле мәҗбүри эшләргә җибәрә алган. Икмәк планы һәр хуҗалыкка тулаем килеш чәчү мәйданыннан чыгып таратыла. Гаиләдәге кеше саны исәпкә алынмый. Кем дә булса развёрстканы үтәми икән, аның планын бөтен авыл халкы үтәргә тиеш була. Мондый коточкыч карар бер илдә дә, бер халыкка карата да кулланылмаган (Таһиров И.Р. Гасырлар чатында. - Казан: Мастер-Лайн, 1998. - Б. 239-240).

Халыкка хәтта чәчү орлыгы да калдырылмый. Нәтиҗәдә план арттырып үтәлә. Алай гына да түгел, Татарстаннан 500 мең потка якын ит, 2 миллион пот чамасы бәрәңге, 30 миллион данә йомырка, 25 мең пот май, 8880 пот бал, 13276 пот йон, 4838 пот җитен, 4639 пот киндер сүсе һәм әле шулар өстенә печән, утын, хәтта 227344 данә тире җыела. Шулай итеп, Татарстан халкы, С.Сәетгалиевнең Совет хөкүмәтенә күрсәткән тырышлыгы нәтиҗәсендә, киләсе 1921 елгы корылык алдында бөтенләй диярлек азык-төлексез калдырыла (Вәлиев Р.К. Өзелгән дога. - Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2007. - Б. 23.) 1920 елда Татарстанда йорт хайваннарының саны 75 процентка кими. Ачлык көчәйгәннән-көчәя бара һәм ул үзе белән тагын бер афәтне китерә. Ул да булса - тиф авыруы. Ачлыкка һәм ялангачлыкка дучар ителгән, зәгыйфьләнгән халык бу коточкыч авыруны җиңә алмый. Үлүчеләрнең саны 1920 елда 218 меңнән дә артып китә.

1921 елда килгән корылык аннан алдагы елга караганда коточкычрак дәрәҗәдә була, әмма ачлык 1921 елның кышында ук коточкыч дәрәҗәгә җитә. Кыш бик салкын килгәнгә, ашарга эзләп чыгучыларның күбесе туңып үлә. Йорт хайваннары суелып бетә диярлек. Авылларда этләр, мәчеләр ашалып бетә... Кабер казырга, мәетләрне күмәргә кешеләрнең көче җитми. Юлда, урамнарда үлеп ятучылар күбәя. Мондый шартларда иң авыр хәлдә калучылар балалар булганын аңлау кыен түгел. 1920 елда Татарстанда барысы 1208875 бала исәпләнә. Алар арасында дүрт яшькә кадәргеләр барысы - 313842, биш яшьтән җиде яшькәчә - 267653 һәм сигез яшьтән алып унбиш яшькә кадәрге 627380 бала була. Шуларның 253892се - ятимнәр, димәк, дәүләт тәрбиясендәге балалар. Тагын Мәгариф һәм Сәламәтлек саклау халык комиссариатларына караган балалар йортларында барысы 36080 бала тәрбиягә алына. Архив материалларында күрсәтелгәнчә, әлеге балаларның да күбесе туйганчы ашаудан мәхрүм ителә, чөнки республикада азык җитешми. Шуның өстенә, күбесенең киемсалымы да бик кызганыч хәлдә, күп балалар салкын тиеп, өшеп үләргә мәҗбүр була.

1922 елның гыйнварына алынган мәгълүматларга караганда, Татарстанда инде барысы 2 млн 400 меңнән артык кеше ачлык афәтеннән интегә. Шушы елның кышында бары бер атна эчендә ачлыктан һәм тифтан үлүчеләр саны 4 мең кешедән артып китә.

Ач балаларны һәм, гомумән, Татарстан халкын коткару өчен берни дә эшләнмәгән дия алмыйбыз. 1921 елда ачлык Идел буе өлкәләренә дә тарала башлагач, Совет хөкүмәте җитәкчеләре, шул исәптән В.Ленин дөнья халкына ярдәм сорап мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була. М.Горький, Америка халкыннан ярдәм сорап, балаларның ачтан тилмерүләре хакында яза.



Ниһаять, 1921 елның 18 июлендә М.Калинин җитәкчелегендә Ачларга ярдәм оештыру буенча Үзәк комиссия (Помгол) төзелә. Шундый ук комиссияләр тиз арада ачлыктан интеккән өлкәләрдә дә оештырыла. Татарстанда 28 июльдә төзелгән комиссияне Башкарма комитет рәисе Рәүф Сабиров җитәкли.

Ачлык вакытында күренекле дин әһелләренең тиңдәшсез фидакарьлекләре хакында әйтмичә булмый. Эчке Россия һәм Себер мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте мөфтие Галимҗан Баруди, ярдәм сорап, бөтен дөньядагы мөселман халкына мөрәҗәгать итәргә дигән карарга килә. Нәзарәт казые К.Тәрҗемани Мәскәүдәге Үзәк комиссия әгъзасы була. Алар ярдәме белән Төркия һәм Мисыр халкыннан ярдәм сорарга күренекле мәгърифәтчеләрдән Таһир Ильяси, Гобәйдулла Буби, ә Төркестанга С.Иманколый китә. Аларның сәфәрләре уңышлы була. Үзе сугыш хәлендә булуга карамастан, Төркия халкының татарлар өчен күрсәткән ярдәме аеруча игътибарга лаек.

Казан губернасыннан 1917 елдан соң чит илләргә китәргә мәҗбүр булган мөһаҗирләребез дә ярдәм оештыра. Бу эштә Казаннан киткән В.Апанаев һәм Троицкида мөгаллимәләр әзерләү мәктәбе ачкан Г.Яушева башлап йөри.

1920 елда Казан шәһәрендә балалар өчен 27 ашханә ачылып, аларда 2400 баланы ашату күздә тотыла. Россиянең икмәкле өлкәләренә озату өчен Казанда Мәгариф комиссариаты каршында эвакуация бюросы оеша. Аның җитәкчесе итеп РКП(б) өлкә комитетының хатын-кызлар бүлеге җитәкчесе һәм Мәгариф комиссариаты коллегиясе әгъзасы Зөһрә Баимбәтова билгеләнә. Урамнарда, пристань, вокзалларда ачлыктан шешенгән, ертык киемнәрдән тәннәрендә җаннары көч-хәл белән сакланып торган балаларга беренче ярдәмне күрсәтү өчен 291 пункт ачыла. Әлеге пунктларда эшләргә РКП(б) өлкә комитетының хатын-кызлар бүлекләре каршындагы делегатлар җыелышлары әгъзалары тартыла. Алар балаларга дарулар, кием-салым һәм хәтта ашханәләр өчен савыт-саба (чөнки ашханәләрнең кайберләрендә 80 балага 1 кашык туры килгән) җыю белән шөгыльләнә. Нәкъ менә алар тырышлыгы белән балалар өчен "Балалар атналыгы", "Кызыл Хач атналыгы", "Ачларга ярдәм итү атналыклары" оештырыла. Икмәкле өлкәләргә озатылачак балаларны башта беттән арындырырга, мунча кертергә, өс киемнәре табарга кирәк була. "Үзләре дә ач хатын-кызлар балаларны коткару өчен чын көрәш фронты ачтылар", - дип яза хатын-кызларны оештыручы, танылган журналист Абруй Сәйфи (Сәйфи А. Татар хатын-кызлары азатлык юлында. - Казан, 1927. - Б. 45).

Балаларны поездларда озата бару да күп кенә очракта хатын-кызларга һәм югары уку йортлары студентларына йөкләтелә. Республикадан барысы 15 меңнән артык бала тиз арада башка төбәкләргә озатыла.

1921 елның 3 сентябрендә Казанга Американың ачлыкка каршы көрәш комиссиясе (АРА) вәкилләре килә. Башында Г.Гувер торган бу комиссия әгъзалары килү белән балалар учреждениеләрен күзәтү астына ала. Алар, үз машиналарына төяп, азык-төлекне кантоннарга озата башлый. "Американлылар алып килгән ризыкның беренче партиясе 50 мең баланы ашатырга җитте, - дип яза "Жизнь национальностей" газетасы. - Тагын 150 мең балага җитәрлек азык-төлек шушы елның 1 октябренә килеп җитәчәк.

*(Ахыры 4 нче биттә.)*

# КАЗАНГА ТАТАР РУХЫ КАЙЧАН КАЙТЫР?

**Казанның Иске татар бистәсендәге кайбер агач йортларны төзекләндерергә вәгъдә итәләр. Һәрхәлдә моңа өмет бар. Шулай да, Татарстан урман хуҗалыгы министрлыгы төзекләндерү турында аңлатмалар бирергә ашыкмый.**

2011 ел азагында узган киңәшмәләрнең берсендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Иске Татар бистәсендәге агач йортларны һичшиксез саклап калырга кирәклеген ассызыклады. "Агачтан салынган йортлар туристларны һәм тарихчыларны җәлеп итә һәм әлеге кызыксыну ел саен арта торачак", - диде республика башлыгы.

Төзекләндерү һәм яңадан төзү эшен (йортларның зур өлеше инде җимерелгән - аларны торгызу мөмкин түгел) Рөстәм Миңнеханов Татарстан урман хуҗалыгы министрлыгына тапшырды. Министрлык карамагына Арча, Саба, Яшел Үзәндә агач эшләре белән шөгыльләнүче берничә оешма керә. Аларда эшләүче осталар тарихи биналарны фоторәсемнәр, эскизлар һәм сакланып калган проектлар буенча торгыза ала. Бер дә гаҗәп түгел: ул осталарның күбесе - авылда туып үскән, балта эшләре белән дус кешеләр.




Тик урман хуҗалыгы министрлыгында төзекләндерү эшләре кайчан башланачагын әле һаман әйтә алмыйлар. "Безнең министрлыкка барлыгы сигез йорт тапшырылды. Тик эшне кайчан башларбыз - үзебез дә белмибез. Чөнки ул йортларның документлары әле әзер түгел. "Белгечләребез бар, алар тарихи йортларны тиешле рәвештә торгыза алачак", дип сөйләделәр "Азатлык" хәбәрчесенә министрлыкның матбугат хезмәтендә.

Беренче чиратта Каюм Насыйри урамы, 24, 26 һәм Габдулла Тукай урамы, 72 нче йорт адресы буенча урнашкан биналарны һәм Шиһабетдин Мәрҗани йортын (К.Насыйри урамы, 10 нчы йорт) төзекләндерү күздә тотыла. Шулай ук, Казанның Киров районындагы Гладилов урамында бер бина да торгызылачак. Ул кайчандыр сәүдәгәр Алафузовлар милке булган.

Биналар төзекләндерелгәннән соң, аларда Татарстан урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы оешмалар урнашачак.

Шиһабетдин ТР Фәннәр академиясенең Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры урынбасары Радик Салихов фикеренчә, төзекләндерәсе йортлар дөрес сайланган.

Мәрҗани мәчете күп кенә туристик маршрутларга кертелгән. Туристлар Каюм Насыйри урамына мәчетне карарга дип килә. Ә мәчет тирәсендә бернәрсә юк. Шуңа күрә әлеге урамда урнашкан 10, 24 һәм 26 нчы йортларның төзекләндерелүен хуплыйм. Бу районда, ниһаять, татарның тарихи панорамасы барлыкка киләчәк дип өметләнәсе килә", дип сөйләде "Азатлык" хәбәрчесенә Р.Салихов.

Агач йортларны, гадәттә, авылдан Казанга күченеп килгән һәм байый алган татар сәүдәгәрләре салдырган. Алар татар йортларына хас бизәкләрне шәһәрдәге яңа йортларында да кулланган. Ягъни, шәһәр шартларында татар мәдәниятен визуальләштергән. Радик Салихов шундый фикердә тора.

"Г.Тукай урамындагы 72 нче йортта урнашкан Бәхтиев йортын төзекләндерү дә бик урынлы. Ул Юнысов мәйданында тора. Ә Юнысов мәйданы хәзер буп-буш. Биредә бер Шамил йорты гына сакланып калган. Мәйданның архитектура ансамблен торгыза алсалар, Иске Татар бистәсенә янә җан керәчәк", - диде Радик Салихов.

***Рамил САФИН***
***Рөстәм Ахунов фотосы***

# КОРЪӘН ЕЛЫ: Болгар чоры изге китап күчермәсе реставрация көтә

*(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)*

1753 елда аңа реставрация ясалган. Ягъни, кәгазь ертылган урыннары башка кәгазь кисәкләре белән ныгытылган, югалган битләр урынына яңалары куелган һәм текст башка катип - китап күчерүче тарафыннан яңадан язылган. Калын тышлыгы да үзенеке түгел. Югалган тышлык урынына, башка китаплардан алынган (бәлки рус китапларыннан калган) күн кисәкләре тупас кына итеп тегеп тышлык ясалган.

Тик яңартканнан соң да китап, күрәсең, начар шартларга эләккән. Аның борынгы оригиналь төп өлеше дә, шулай ук реставрацияләнгән урыннары да дымнан бозылган . "Яңа" тышлык кечерәк булу сәбәпле ул битләрне тиешенчә каплап җиткерми, шуңа күрә бит кырыйларын яхшы сакламаган, чит-читләре таушалып ертылган.

Текст каллиграф тарафыннан бик оста һәм матур итеп "нәсх" стилендә язылган. Һәр биттә 13 юл. Җентекләп карагач, реставрация ясаган кешенең язулары камиллек ягыннан бераз калышканы сизелә.

Элеккеге заманнарда изге китапны күчерүчеләр үз исемнәрен күрсәтмәгәннәр. Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән сүзләрдән соң кеше исемен язу килешми, дип саналган. Әмма бик сирәк очракларда бу кагыйдә бозылган. Әлеге борынгы Корьән моңа бер мисал. Китап ахырында шактый кызыклы мәгълүмат сыйдырган 8 юллык язу бар. Андый язуларны фәнни телдә колофон дип йөртәләр.



Кулъязма Корьәндә колофонны реставрация ясаган кеше язарга җөрьәт иткән. Язу асылда фарсы телендә гарәп һәм иске татар сүзләрен кулланып язылган. Нурия ханым әйтүенә караганда, аны я фарсыча, я гарәпчә генә итеп укып булмый. Нәкъ менә безнең җирлек теленә яраклаштырырга кирәк икән. Фарсы өлешендә гарәп сүзтезмәләре һәм татар сүзләре булу исә колофонны татар кешесе язганны исбатлый. Нәкъ менә татар катибләренә колофон язганда өч телне куллану хас. Әлбәттә, бу язу да шактый зыян күргән, урыны-урыны белән кайбер сүзләре бөтенләй укылмый. Шулай да белгеч, аны тикшереп, эчтәлеген аңлап билгеле бер фикергә килгән.

Монда төрле чорга караган мәгълүматлар бирелә. Текстан аңлашылганча, китапны Абдуллаһ бине мулла Ырыс-Мөхәммәд исемле кеше 1265/1752-1753 елда Болгар тирәсендә яшәгән Әбд әл-Җәлил мулла улы өчен яңарткан.

Колофонның икенче өлешендә Болгар шәһәре Аксак Тимер тарафыннан җимерелү вакыты 640/1242-1243 ел дип языла. Тик тарихта Аксак Тимернең Болгарны җимерүе бәхәсле факт булып тора. Тарихчы профессор Миркасыйм Госманов хезмәтендә Болгарның рус чыганакларында соңгы тапкыр 1341 елда телгә алынуы әйтелә - рус кнәзе Чуар Федор (Пёстрый) җитәкләгән гәскәр һөҗүменнән соң Болгар шәһәр буларак торгызылмый.

Өченче өлеш - текстның соңгы юлында китапны күчерү 525 елда, ягъни милади белән 1131 елда тәмамлану турындагы сүзләр бар. Колофонның бу өлеше бик сирәк табышка тап булуыбызны күрсәтә. Безгә килеп җиткән "Каләме шәриф" кулъязмасы XVII гасырга караса да, ул күчереп язар өчен үрнәк (протограф) итеп алынган Корьән кулъязмасының 525/1131 елда язылганын дәлилли. Ягъни, бу кульязма Болгар җирендә кулланышта булган Корьән нөсхәсенең күчермәсе, дип фаразларга мөмкин.

Курган өлкәсендә табылган Корьән кулъязмасы турында сөйләшкәндә Нурия ханым: "Бу кулъязманы тәфсилләп карасаң күренә ки: Корьән авыр шартларда күчерелгән, катип иркенләп, тыныч эшли алмаган. Хәттә кайбер урыннарында күчерүче ялгышлыклар җибәреп, аларны төзәтер өчен текстны яңадан кабатлап язган, алай да үз эшен бетерә алмаган. Мәсәлән, язмада сүрә исемнәре дә язылмыйча калган. Аларны соңрак башка бер катип өстәп яза, ләкин аның осталыгы кулъязманың асыл текстындагы зәвыктан калыша", - дигән сүзләрне дә әйтте.

## Саклау - ул яңарту дигән сүз...

Тагын бер мәгълүмат турында әйтеп китү урынлы булыр. Колофон читендә кулъязманың 1864 елдан Әбд әл-Әхәт исемле яңа хуҗага күчүе әйтелә. Танылган дин белгече Ризаэддин Фәхретдин үзенең "Асар" дип аталган биобиблиографик хезмәтендә менә шушы кеше һәм аның әтисе Әбд ән-Насыйр турында яза. Алар икесе дә Әлмән авылында туган, танылган шәхесләр булган. Әбд ән-Насыйр әл-Әлмәни дәрәҗәле татар катибе булган, 95 яшендә дөнья куйган. Егерме яшеннән китаплар күчерә башлаган, гомере буе барлыгы 223 том китап күчерә. Аның улы Әбд әл-Әхәт Әлмән авылында имам-мөдәррис вазифаларын башкарган. Әлбәттә, ул әтисе кебек катиб булмаса да, дини китапларны кадерләп саклауга зур өлеш керткән шәхес.

Бүгенге көндә менә шундый рухи байлык сагында торучылар ярдәмендә килеп ирешкән татарларның уникаль кулъязмалары саклауга мохтаҗ. Ә инде аларның киләсе буыннарга да барып ирешүен теләсәк, саклау белән бергә яңарту турында җитди уйларга кирәк. Реставрация ясау - көн тәртибендә торган җитди мәсьәлә. Гарәп илләре дә реставрация җиһазларын булдыруда ярдәм итәргә вәгъдә итә икән. Кульязмаларның бозылган, югалган өлешләрен хәзерге технологияләр белән торгызып була. Китапханәчеләр, Аллаһ боерса, Курган өлкәсеннән табылган уникаль кулъязма да бик матур нөсхәгә әйләнер дип өмет итә. Ул - татар мөселманнарының XVII гасырга кадәрге чорга караган һәм безнең көннәргә килеп җиткән игътибарга лаек рухи байлыгы булып тора бит.

***Айзирәк ГӘРӘЕВА***

# Ачлык елында балалар язмышы

*(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)*

Моның өстәвенә комиссия вәкилләре Татарстанга дарулар да китерәчәкләрен әйттеләр".

Америка халкының республикабызга ярдәме зур була, әлбәттә. Озак еллар дәвамында бу ярдәм хакында оныттырырга тырышсалар да, ачлыктан котылучылар аны онытмады. Хәтеремдә, өлкәннәр безгә, балаларга ул ярдәм хакында рәхмәтләр белән елый-елый искә алалар иде.

Татарстаннан читкә озатылган балаларның барысы да кире туган җирләренә әйләнеп кайта алганнардыр дип тә әйтә алмыйбыз әле. Дөрес, ачлык нәтиҗәләре белән көрәш комиссиясе балалар озатылган урыннарга аларны кире кайтару хакында хәбәрләр җибәргән үзе. "Кире кайтарылган 20 мең балага урын әзерләнде", - дип тә хәбәр итә "Татарстан" газетасы. Кире кайтару эше Мәгариф Халык комиссариатына тапшырыла, әмма комиссариатның матди мөмкинлекләре ни дәрәҗәдә булганы ачык түгел. Шулай да мәгариф хезмәткәрләренең балалар язмышына хәлдән килгәнчә ярдәмнәре хакында кайбер мәгълүматлар бар. "Татарстан" газетасында басылган бер хәбәрдә дә бу ачык күренә. Анда болай диелә: "Узган ел ачлык сәбәпле, берничә йөз бала Чехословакиягә күчерелгән иде. Чехословакия вәкилләре аларны андагы игенчеләрнең балалыкка алырга теләкләрен белдергән. Мәркәз комиссиясе аларның үтенечләрен кабул итмәде һәм балаларны кайтару чараларын күрүне Мәгариф Халык комиссариатына йөкләде. Кайта алмаган балалар хакында Зөһрә апа Баимбетова болай дип сөйләгән иде: "Мине 1922 елда Татарстаннан Бохара республикасына эшкә җибәрделәр. Бер дә китәсем килмәгән иде. Киткәч тә, һаман шул балалар күз алдымда торды. Юкка булмаган икән. Берничә елдан соң Кисловодскида ял итеп, сеңлем белән Мәскәүгә кайтып барышлый вокзалда утырабыз. Безнең татарча сөйләшкәнне ишетеп, сәләмә киемнәрдән бер үсмер бала килде. Елыйелый: "Апа, Сез Зөһрә апаны белмисезме, безне Казаннан җибәргәндә, кайтарам дип вәгъдә биргән иде. Кайта алмадык бит менә. Мин монда бер байда ялчы булып хезмәт итәм, туйганчы ашый да алганым юк", - дип үзәгемне өзде. Кемлегемне әйтергә оялдым". Бу истәлек тә халкыбыз кичергән гаять зур фаҗига хакында сөйли бит.

Бу ачлык республикада мәңге онытылмаслык тирән эзләрен калдыра. Әйе, 1921-1922 елларда 326 мең баланың ачлыктан үлүе (История Татарстана. Учебное пособие для основной школы. - Казань: ТаРИХ, 2001. - С.347) беркайчан да онытылырга тиеш түгел. Байлыкта юклыкны, туклыкта ачлыкны онытмаска куша халык мәкале. Киләчәк буын ачлыкны китереп чыгаруда кемнәр гаепле икәнен дә хәтереннән җуймаска тиеш.

***Тәэминә БИКТИМЕРОВА,***
***тарих фәннәре кандидаты,***
***Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре***

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 28.01.2012 | 7:16 | 8:46 | 13:02 | 15:46 | 17:08 | 18:38 |
| Якшәмбе | 29.01.2012 | 7:14 | 8:44 | 13:02 | 15:47 | 17:10 | 18:40 |
| Дүшәмбе | 30.01.2012 | 7:13 | 8:43 | 13:02 | 15:48 | 17:11 | 18:41 |
| Сишәмбе | 31.01.2012 | 7:11 | 8:41 | 13:02 | 15:50 | 17:14 | 18:44 |
| Чәршәмбе | 1.02.2012 | 7:09 | 8:39 | 13:02 | 15:51 | 17:16 | 18:46 |
| Пәнҗешәмбе | 2.02.2012 | 7:07 | 8:37 | 13:02 | 15:53 | 17:18 | 18:48 |
| Җомга | 3.02.2012 | 7:05 | 8:35 | 13:02 | 15:55 | 17:21 | 18:51 |
| Шимбә | 4.02.2012 | 7:03 | 8:33 | 13:02 | 15:56 | 17:23 | 18:53 |

## "Китапка хөрмәт Корьәннән башланган"

***26 гыйнвар көнне ТР мөселманнары Диния нәзарәтендә Корьән елын үткәрү буенча оештыру комитеты уздырган беренче утырышта ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев әнә шулай дип белдерде.***

Утырышта шулай ук Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз, ТР Президенты Аппараты җитәкчесе урынбасары - ТР Дәүләт Киңәшчесе секретариаты башлыгы Җәүдәт Салихов, ТР Президентының Дини берләшмәләр белән бәйләнешләр идарәсе башлыгы Марат Гатин, ТР Фәннәр академиясе президенты Әхмәт Мазһаров, министрлык-ведомстволар җитәкчеләре, дин әһелләре, җәмәгать эшлеклеләре катнашты.



**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №4 (121) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-524.
**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 26 гыйнвар көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Корьәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**